МИНИСТЕРСТВО ЭКОНОМИКИ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ИКЪТИСАД МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

28.04.2026 Казан шәһәре 75

Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу комиссиясе турында "Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу комиссиясе турында Нигезләмәне раслау хакында" 22.05.2018 ел, № 232 Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы боерыгы белән расланган Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында

Норматив хокукый актны "Татарстан Республикасы Президентының коррупциягә каршы көрәш мәсьәләләре буенча аерым указларына үзгәрешләр кертү һәм Татарстан Республикасы Президентының аерым указларының һәм Татарстан Республикасы Рәисенең аерым указларының үз көчләрен югалтуын тану турында" Татарстан Республикасы Рәисенең 2026 елның 09 апрелендәге 278 номерлы Указына туры китерү максатларында боерык бирәм:

"Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу комиссиясе турында Нигезләмәне раслау хакында" 22.05.2018 ел, № 232 Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә

таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу комиссиясе турында Нигезләмәгә (Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының 07.10.2022 № 359, 09.03.2023 № 57, 25.08.2023 № 180, 08.07.2024 № 138 боерыклары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

6 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“6. Комиссия Министрлык боерыгы белән төзелә. Күрсәтелгән боерык белән Комиссия составы һәм аның эш тәртибе раслана, Комиссия рәисе, аның урынбасары, секретаре билгеләп куела һәм Комиссиянең башка әгъзалары билгеләнә. Комиссиянең барлык әгъзалары карарлар кабул иткәндә тигез хокукларга ия. Комиссия рәисе булмаганда аның вазыйфаларын Комиссия рәисе урынбасары башкара.»;

7 пунктның “а” пунктчасында “(Комиссия рәисе),” сүзләреннән соң “Министрлыкта дәүләт хезмәте вазыйфасын биләүче зат (Комиссия рәисе урынбасары)” сүзләрен өстәргә;

9 пунктның икенче җөмләсен төшереп калдырырга;

15 пунктның “а” пунктчасының икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“Татарстан Республикасы Президентының 2009 елның 30 декабрендәге ПУ-702 номерлы Указы белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар һәм Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү хакында Нигезләмәдә каралган дөрес булмаган яисә тулы булмаган белешмәләрне дәүләт хезмәткәрләренә бирү турында;”;

21 нче пунктның “а” пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“а) Татарстан Республикасы Президентының 2009 елның 30 декабрендәге ПУ-702 номерлы Указы белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар һәм Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү турында Нигезләмә нигезендә дәүләт хезмәткәре тарафыннан тапшырылган белешмәләр дөрес һәм тулы дип билгеләргә;”.

**Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары –**

**министр** **М. Р. Шаһиәхмәтов**